ГЛАВА БАЙРЯКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ютазинская, д.14А,
с.Байряка, 423963

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БӘЙРӘКӘ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Ютазы урамы, 14А йорт,
Бәйрәкә авылы, 423963

Тел.:(85593) 2-44-12, факс: 2-44-13, e-mail: Bay.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 11** **06 декабрь 2021 ел**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлегендәге Бәйрәкә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы карарының 25.1, 56 санлы маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге Уставының 14 маддәсе нигезендә, Ютазы муниципаль районы «Бәйрәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елның 17 декабрендә 14.00 сәгатьтә Бәйрәкә авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган Абдуллин, Авангард, Вахитов, Кооперация, Мингазов урамнарында яшәүчеләр өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыелышының беренче этабын билгеләргә.
2. 2021 елның 20 декабрендә 10.00 сәгатьтә Бәйрәкә авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган Октябрь, Пушкин, Сельхозтехника, Татарстан урамнарында яшәүчеләр өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыелышының икенче этабын билгеләргә.
3. 2021 елның 20 декабрендә 14.00 сәгатьтә Бәйрәкә авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган Тукай,Ютазы, 1 Май,8 Март урамнарында яшәүчеләр өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыелышының өченче этабын билгеләргә.
4. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге башкарма комитеты оештыра дип билгеләргә;

- җыенның беренче этабы 2021 елның 17 декабрендә 14.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр;
- җыенның икенче этабы 2021 елның 20 декабрендә 10.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр;
- җыенның өченче этабы 2021 елның 20 декабрендә 14.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр;
- уздыру урыны – Бәйрәкә авылы, октябрь урамы, 1А йорт, авыл мәдәният

йортында;

5. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге башкарма комитетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- 2021 елның 15 декабреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыенын хәл итү өчен чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын түбәндәге адрес буенча бирергә: Бәйрәкә авылы, Ютазы урамы, 14А йорт;

- сайлау хокукына ия Бәйрәкә авылында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Бәйрәкә торак пунктына халыкка массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән гражданнар җыены турында хәбәр итәргә.

6. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

«2022 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге Бәйрәкә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, ветераннар һәм Бөек ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган тормыш иптәшләренннән тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә, түләү суммасын 250 (ике йөз илле) сумга киметеп, 2 төркем инвалидларга үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Юлларны грейдерлаштыру һәм кардан чистарту (ягулык сатып алу, трактористы белән техника арендалау, килешү нигезендә эшләр өчен түләү);
- Бәйрәкә авылының Пушкин урамындагы юл-урам челтәрен норматив торышка китерү (смета нигезендә юл төзү: вак ком-таш катнашмасы, асфальт сатып алу, нигез әзерләү, алып кайту, салу, эшләр өчен түләү);
- Бәйрәкә авылының административ бина территориясен төзекләндерү (койма урнаштыру, килешү нигезендә эшләр өчен түләү; агачлар, чәчәкләр, куаклар сатып алу һәм утырту);
- Бәйрәкә авылындагы 8 Март урамында урнашкан зират территориясе коймасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр өчен килешү нигезендә түләү);
- Бәйрәкә авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергияне саклаучы лампалар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам яктырткычларына хезмәт күрсәтү);
- Бәйрәкә авылында корыган агач, куакларны кисү, авыл территориясен җыештыру (килешү нигезендә эшләр өчен түләү);
- Бәйрәкә авылында Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчылар монументына алып баручы парад баскычын алыштыру (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр өчен түләү, килешү нигезендә эшләр өчен түләү).

«ӘЙЕ »　　　　　　« ЮК »

7. Әлеге карарны кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, http://pravo.tatarstan.ru электрон адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Бәйрәкә авыл җирлеге
башлыгы　　　　　　А.О.Әхмәтшина